Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Керкәле авыл җирлеге
Керкәле авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2021 елның 20 ноябре № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 20 ноябрендә 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән, студентлар һәм ташламадан файдаланудан тыш, 300 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

- Керкәле авылы М. Җәлил урамнарындагы юлларны өлешчә ремонтлау
- Керкәле авылында кышкы чорда юлларны кардан чистарту
- Керкәле авылы, Совет урамында спорт мәйданчыгы

«ӘЙЕ» «ЮК».

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 577 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 298 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар бертавыштан «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирделәр.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле авылында гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлеге составына керүче Керкәле авылында гражданнар җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән, студентлар һәм ташламадан файдаланудан тыш, 300 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

- Керкәле авылы М. Җәлил урамнарындагы юлларны өлешчә ремонтлау
- Керкәле авылында кышкы чорда юлларны кардан чистарту
- Керкәле авылы, Совет урамында спорт мәйданчыгы соравы буенча карарны кабул ителгән, дип таныргa.

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Керкәле авылы, Советская урамы, 93 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Керкәле авыл җирлеге башлыгы Г.Х.Шириязданова